**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 март № 146

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2010 ел, 24 август, 678 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 8 октябрь, 790 нчы; 2010 ел, 3 декабрь, 987 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1175 нче; 2011 ел, 28 апрель, 347 нче; 2011 ел, 30 апрель, 356 нчы; 2011 ел, 25 июль, 576 нчы; 2011 ел, 19 август, 688 нче; 2011 ел, 19 сентябрь, 778 нче; 2012 ел, 20 гыйнвар, 31 нче; 2012 ел, 25 апрель, 323 нче; 2012 ел, 1 июнь, 464 нче; 2012 ел, 31 октябрь, 932 нче; 2012 ел, 31 декабрь, 1186 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 50 нче; 2013 ел, 29 апрель, 298 нче; 2013 ел, 29 июнь, 457 нче; 2013 ел, 26 август, 600 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 796 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1105 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 октябрь, 791 нче; 2015 ел, 20 февраль, 104 нче; 2015 ел, 10 март, 140 нчы; 2015 ел, 8 апрель, 230 нчы; 2015 ел, 16 май, 350 нче; 2015 ел, 14 август, 591 нче; 2015 ел, 25 ноябрь, 889 нчы; 2015 ел, 30 декабрь, 1031 нче; 2016 ел, 26 гыйнвар, 38 нче; 2016 ел, 13 май, 314 нче; 2016 ел, 20 июль, 491 нче; 2016 ел, 30 сентябрь, 698 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2 бүлектә:

2.4 нче пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

$$«O_b = T_1 \times K_{m_i},»;$$

җиденче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

2.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары, сәнгать-эстетика, күппрофильле һәм спорт юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмалары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен мәгариф оешмалары педагогик хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керә торган хезмәткәрнең база оклады түбәндәге формула буенча исәпләнә :

$$O_b = T_1 \times K_{m_i} \times K_{m_j} + P,$$

монда:

$K_{m_j}$ – тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты;

$P$ – китап-басма продукция һәм вакытлы матбугат белән тәэмин итүгә 100 сум күләмендәге компенсация, уку-укыту нагрузкасына пропорциональ рәвештә, әмма төп эш урыны буенча бер ставкадан арттырмыйча билгеләнә.

Тармак өстенлегенең арттыру коэффициенты күләме педагогик хезмәткәрләрнең база окладын хисаплап чыгару өчен кулланыла һәм түбәндәгеләрне тәшкил итә:

мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча төп гомуми белеме, урта гомуми белеме һәм урта һөнәри белеме булган хезмәткәрләр өчен – 1,000;

урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белеме булган хезмәткәрләр өчен – 1,166;

бакалавриат – югары белеме булган хезмәткәрләр өчен – 1,223;

белгечлек яки магистратура – югары белеме булган хезмәткәрләр өчен – 1,166;

гомуми белем бирү оешмаларында:

беренче, икенче, өченче квалификация дәрәҗәләрендәге педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәренә керә торган түбәндәге хезмәткәрләр өчен:

квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча төп гомуми белеме, урта гомуми белеме һәм урта һөнәри белеме булган – 1,000;

урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белеме булган – 1,200;

бакалавриат – югары белеме булган – 1,258;

белгечлек яки магистратура – югары белеме булган – 1,200;

дүртенче квалификация дәрәҗәсендәге педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр өчен – 1,029;

һөнәри белем бирү оешмаларында – 1,248;

гамәлгә куючының норматив хокукый актлары белән һөнәри белем бирү буенча тармак ресурс үзәкләре статусы бирелгән һөнәри белем бирү оешмаларында – 1,328;

сәнгать-эстетика, күппрофильле һәм спорт юнәлешендәге өстәмә белем бирү оешмаларында – 1,565;

ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен мәгариф оешмаларында – 1,362.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының физик культура һәм спорт хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

2 бүлекнең 2.4 нче пунктындагы җиденче абзацта «1,155» саннарын «1,565» саннарына алмаштырырга;

5 бүлектә:

3 таблицага түбәндәге эчтәлекле 80 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «80 | Джиу-джитсу | 1,5 | 2,0 | 2,4 | 4,6 | 4,6 | 6,5 | 6,5 | | 17,0 | 23,0 | 35,0»; |

4 таблицада:

10 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «10 | Велоспорт-маунтинбайк | 4 | 6 | 9 | 12 | 14 | 16 | 18 | 18 | 24 | 26 | 30»; |

түбәндәге эчтәлекле 80 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «80 | Джиу-джитсу | 4 | 5 | 6 | 10 | 10 | 14 | 14 | | 20 | 20 | 24»; |

5 таблицага түбәндәге эчтәлекле 80 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «80 | Джиу-джитсу | 15 | 14 | 14 | 12 | 12 | 12 | 12 | | 4 | 4 | 2». |

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\146.doc